ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ «ГОРОД БАВЛЫ»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

18.08.2021 Баулы шәһәре №85

Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының кайбер карарларын юкка чыгару турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 10-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты норматив хокукый актларга туры китерү максатларында

КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының:

- “Татарстан Республикасы “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәт исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукыннан азат һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм Татарстан Республикасы “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлегенә кертелгән муниципаль мөлкәтне арендага бирү тәртибен һәм шартларын раслау турында” 2017 елның 25 декабрендәге 49 номерлы карары;

- “Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга биләүгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән, өченче зат хокукларыннан азат (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль мөлкәте исемлеген булдыру, алып бару, бастырып чыгару тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында” 2017 елның 25 декабрендәге 50 номерлы карар.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

«Баулы шәһәре» муниципаль
берәмлеге башкарма комитеты
җитәкчесе Д.Л. Бакиров